| ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕ |
|---|---|---|
| ПРИКАЗ | | БОЕРЫК |
| __18.02.2022_______ | Казан шәһәре | №__29_____ |

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2016 елның 7 апрелендәге 26 санлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе каршындагы иҗтимагый шура турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый шура турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 906 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый шура турында бертөр нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 26 гыйнварындагы 54 санлы карары чыгуга бәйле рәвештә

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2016 елның 7 апрелендәге 26 санлы боерыгы (Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 25.10.2017 №115, 05.06.2019 №66, 08.12.2021 №118 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе каршындагы иҗтимагый шура турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6.6 пунктның икенче кызыл юлына «әлеге пунктның беренче кызыл юлында күрсәтелгән тәкъдим алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнгән биш көнлек чорда» сүзләрен өстәргә;

6.7 пунктның икенче кызыл юлына «әлеге пунктның беренче кызыл юлында күрсәтелгән тәкъдим алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнгән биш көнлек чорда» сүзләрен өстәргә;

6.8 пунктның икенче кызыл юлына «әлеге пунктның беренче кызыл юлында күрсәтелгән тәкъдим алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнгән биш көнлек чорда» сүзләрен өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең Хокукый эш һәм өлешле төзелешне тикшерүдә тоту идарәсенең хокук бүлегенә әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең җыелма анализ һәм мәгълүмат технологияләре бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең рәсми сайтында урнаштырырга.

Җитәкче В.А. Кудряшов